ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.03.2019 334

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территорияләрен муниципаль гомуми белем бирү оешмаларына беркетү турында" 2019 елның 29 гыйнварындагы 101 нче санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында " Федераль Законның 67 маддәсенә, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының "Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга гражданнарны кабул итү тәртибен раслау турында" гы 2014 елның 22 нче гыйнварындагы 32 санлы боерыгы нигезендә һәм гражданнарның мәгарифкә конституциячел хокукларын яклауны тәэмин итү, гомуми белем бирү оешмаларының санлы составын тәртипкә салу максатларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территорияләрен муниципаль гомуми белем бирү оешмаларына беркетү турында"гы 2019 елның 29 гыйнварындагы 101 нче санлы карарына үзгәрешләр кертергә:

- карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"2019 нчы елга Алабуга муниципаль районы территорияләрен муниципаль гомуми белем бирү оешмаларына беркетү турында»;

- 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш»;

- 4 пунктны түбәндәге редакциядә өстәргә «Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Н. Рыбаковага йөкләргә».

2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территорияләрен муниципаль гомуми белем бирү оешмаларына беркетү турында» 2018 елның 24 гыйнварындагы 73 нче санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Рыбаковка Л. Н. йөкләргә.

Җитәкче Р.С. Хәйруллин